**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **21 ноябрь 2019 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
Районы Туйкә авыл җирлеге составына керүче
Камышлы Күл поселогында 2020 елда
гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Камышлы Күл поселогында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Туйкә авыл җирлеге Камышлы Күл торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (Бер мең) сум күләмендә, 2 группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 500 (Биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- Камышлы Кул авылы, Ленин урамы буенча юлларга вак таш (щебенка) җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, эшләр өчен килешү буенча түләү);
- Камышлы Күл авылында Ленин урамы исеме белән күрсәткечләр сатып алу;
- Камышлы Күл авылында юлларны кардан чистарту;
- үзәкләштерелгән чыганаклардан эчә торган суны анализлау: «Салкын Чишмә» чишмәсе;
- Камышлы Күл авылында «Авыл бәйрәме»н үткәрү өчен бүләк, сувенир продукциясе сатып алу, хезмәт күрсәтү;
- Камышлы Күл авылы Ленин урамы юлының техник паспортын ясату;
- Камышлы Күл авылы зиратының җир кишәрлеген ызанлау.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Туйкә авыл җирлеге Башлыгы Закирова Р.Р.